Татарстан Республикасы
Әлмәтмуниципаль районы
Бута авылбашкарма комитеты

КАРАР

4 август 2023 ел № 6

Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыннары турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган тиешсез урындаҗыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру кагыйдәләрен раслаутурында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә,Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 30 июнендәге 754 номерлы күрсәт мәсен карап

Бутаавыл башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, яктырту җайланмаларын, электр лампаларын гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган тиешсез урында җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортировкалау, урнаштыру кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Кагыйдәнең 4 пункты нигезендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларнытуплау урыннарын билгеләргә, шул исәптән, күп фатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмаганга туплау мөмкин булмаган очракларда, шулай ук кулланучыларга мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат бирергә.

2. Татарстан Республикасы, Әлмәтмуниципаль районы, Бута авыл җирлеге, Бута авыл,Сельская ур., 13йорт, кв. 2, адресы буенча кулланылышта булган терекөмешле лампаларны туплау урыны итеп махсус тартма билгеләргә.

3. Әлмәт муниципаль районы Бута авыл башкарма комитетының «Бута авыл җирлеге территориясендә кулланылышта булган терекөмешле лампаларны беренчел җыюны һәм урнаштыруны оештыру турында»2016 елның 28 октябрендәге 12 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарныТатарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Бута авыл,ул.Сельская,д.28А,территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соңүз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Бута
авылбашкарма комитеты җитәкчесе Д.Е. Абрамов